| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

20.09.2013 — № 5-18/тэ

Казан ш.

***Кулланучыларга «Индустриаль парк-Сервис» идарә компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында***

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар буенча хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә кулланучыларга «Индустриаль парк-Сервис» Идарә компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. »Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 11 март, 2012 ел, № 5-5/э Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарын 2013 елның 1 октябреннән үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис — М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.09.2013 № 5-18/тэ
карарына кушымта

Кулланучыларга «Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар

(НДС исәпкә алмыйча)

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|
| | | | су | пар |
| Кулланучыларга җиткерелә торган җылысаклагычка тариф | | | | |
| 1 | «Индустриаль парк-Сервис» идарәче компаниясе» ҖЧҖ | Бер ставкалы, сум/куб.м | 117,56 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге